**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**15 нче июнь 2020 ел** **№ 151**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында**

2019 елның 12 ноябрендәге 367-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлешенең үзенчәлекләрен билгеләү турында» гы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы «Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 14 сентябрендәге 42 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 3 пунктының, 86 статьясындагы 5 пунктының (бюджет үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерләү сроклары өлешендә) гамәлен 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;
- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43,
- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы, Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге Советы рәисе Ф.Г. Гарифуллин